**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.08.2019 № 612

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 елның 22 сентябрендәге 577 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 12 августындагы «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 660нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 елның 22 сентябрендәге 577 номерлы карары (2018 елның 27 ноябрендәге 1004 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә (алга таба - тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктына «Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегендә каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның 8 пунктчасы үз көчен югалткан дип таныргa;

9.1 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

14 пунктта «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х. Хәбибулловага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин